Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVI-7**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 13 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы регламентын раслау турында”гы XXXVI-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы регламентын раслау турында”гы XXXVI-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 маддәнең 2 пунктындагы “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга;

59 маддәнең 1 пунктындагы 15 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов